**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**СОВЕТ МОНАСТЫРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ТЕТЮШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

422392, Республика Татарстан, Тетюшский район, с. Монастырское, ул. Комсомольская, д. 33

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТӘТЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ МОНАСТЫРСК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

422392, Татарстан Республикасы, Тәтеш районы, Монастырск авылы, Комсомол урамы, 33

Тел. (84373)5-45-20, факс: 5-45-20, e-mail: monastyr.tetushi@tatar.ru
ОКПО 92655464, ОГРН 1021606556883, ИНН/КПП:1638001649/163801001

# КАРАР

**2019 елның 10 июле** **47-1**

## Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Монастырск авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының законнарга һәм муниципаль норматив хокукый актларына үзгәрешләр кертү мониторингын үткәрү турындагы нигезләмәне раслау хакында

Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Монастырск авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы җирле үзидарә органнары тарафыннан кабул ителгән законнарның һәм муниципаль норматив хокукый актларына үзгәрешләр кертү мониторинг үткәрү буенча эшен камилләштерү максатларында, “Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы “Монастырск авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Монастырск авыл җирлеге Советы **КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Монастырск авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының законга һәм муниципаль норматив хокукый актларына үзгәрешләр кертү мониторингын үткәрү турында нигезләмәне расларга (кушымта итеп бирелә).

2. Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Монастырск авыл җирлеге җирле үзидарә органнарына:

үзенең эшчәнлегендә әлеге карарның 1 нче пункты белән расланган нигезләмәгә таянып эш итәргә;

күрсәтелгән нигезләмәне үтәү өчен җаваплы затларны билгеләргә;

җаваплы затлар буларак билгеләнгән муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи күрсәтмәләренә тиешле үзгәрешләр кертергә.

3. Әлеге карарны Тәтеш муниципаль районының рәсми сайтында һәм “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар рәсми порталында” (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үзем артыннан калдырам.

5. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән ун көн узгач үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Тәтеш муниципаль районы**
**Монастырск авыл җирлеге башлыгы Г.И. Костягин**

Тәтеш муниципаль районы
Монастырск авыл җирлеге Советының
2019 елның 10 июлендәге
47-1 карарына 1 нче кушымта

## Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Монастырск авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының законнарга һәм муниципаль норматив хокукый актларына үзгәрешләр кертү мониторингын үткәрү турында нигезләмә

### I. Гомуми нигезләмәләр

1. Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Монастырск авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының законга һәм муниципаль норматив хокукый актларына үзгәрешләр кертү мониторингы (алга таба мониторинг, муниципаль актлар, җирле үзидарә органнары) муниципаль актларны үзгәртү яисә үз көчен югалткан дип тану өчен мәгълүмат җыю, гомумиләштерү, анализлау һәм бәяләү буенча үз вәкаләтләре чикләрендә җирле үзидарә органнары тарафыннан гамәлгә ашырыла торган системалы, комплекслы һәм планлы эшчәнлекне күз уңында тота.

2. Мониторинг җирле үзидарә органнары тарафыннан үткәрелә.

3. Җирле үзидарә органнары мониторинг үткәргән вакытта Тәтеш муниципаль районы башкарма комитетының оештыру эше секторы, Тәтеш муниципаль район Советы аппаратының оештыру бүлеге һәм муниципаль берәмлекнең башка җирле үзидарә органнары белән хезмәттәшлек итә.

4. Җирле үзидарә органнарында мониторинг үткәрү өчен җаваплы затлар билгеләнә.

5. Мониторинг үткәрүнең максатлары булып торалар:

муниципаль актларны федераль һәм республика законнарына туры китерү максатларында кабул итү, үзгәртү яки үз көчен югалткан дип тану;

муниципаль актларда каршылыкларны, пробелларны бетерү, хокукый җайга салуда кабатлануны тәэмин итү;

җирле үзидарә органнарының норматив хокукый базасын системалаштыруны тәэмин итү;

муниципаль актларда коррупциоген факторларны ачыклау;

ихтыяҗ булмаган (актуальлекне югалткан) яисә практикада кулланылмаган муниципаль актларны яисә аларның аерым нигезләмәләрен (нормаларын) ачыклау;

хокукый куллану нәтиҗәлелеген арттыру;

муниципаль актларны гамәлгә ашыруның нәтиҗәлелеген киметә торган факторларны ачыклау;

муниципаль актлар үтәлешен җирле үзидарә органнарының тиешле бүлекчәләре тарафыннан тикшереп торуны гамәлгә ашыруга ярдәм итү;

нормалар чыгару процессын камилләштерү буенча тәкъдимнәр эшләү.

6. Мониторинг җыю, гомумиләштерү, анализ һәм бәяләү кебек үзгәрешләрне үз эченә ала:

федераль конституцион законнар, федераль законнар, Россия Федерациясенең башка закон актларын;

Россия Федерациясе Президенты указлары, Россия Федерациясе Хөкүмәте карарлары, федераль башкарма хакимият органнарының норматив хокукый актлары, федераль дәрәҗәдәге башка законга кагылышлы норматив хокукый актларын;

Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актларын;

Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы норматив хокукый актларын;

“Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы “Монастырск авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставы, муниципаль актларын.

7. Мониторинг үткәрүнең нигезләре булып торалар:

федераль һәм республика законнары актларына үзгәрешләр кертү;

хокукый җайга салу өлкәсендә муниципаль актларны куллануны анализлау;

прокуратура органнары мәгълүматы;

муниципаль актларның җитешсезлекләре яки камилләштерү зарурлыгы турында массакүләм мәгълүмат чаралары мәгълүматы;

гражданнарның, юридик затларның, шул исәптән иҗтимагый, фәнни, хокук саклау һәм башка оешмаларның, шәхси эшкуарларның, дәүләт хакимияте органнарының, муниципаль берәмлекләрнең вәкиллекле органнары депутатларының муниципаль актларның камил булмавы турында мөрәҗәгатьләре, шул исәптән:

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы тарафыннан Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертелгән муниципаль актларга карата үткәрелгән хокукый экспертиза бәяләмәсе;

билгеләнгән тәртиптә вәкаләтле затлар тарафыннан әзерләнгән муниципаль актларга коррупциягә каршы экспертиза бәяләмәләре;

җирле үзидарә органнары үткәрә торган конференцияләрнең, семинарларның, гаммәви тыңлаулар, җәмәгать фикер алышуларының һәм башка чараларның йомгаклау документлары.

## II. Мониторинг үткәрү тәртибе

8. Җирле үзидарә органнары әлеге нигезләмәнең 4 пунктында күрсәтелгән җаваплы затлар белән үзара бәйләнештә аларның компетенцияле мәсьәләләре буенча мониторинг үткәрәләр.

Мониторинг үткәрү максатларында эшче төркемнәр төзелергә, киңәшмәләр, консультацияләр үткәрелергә, кирәкле мәгълүмат соратып алынырга, Татарстан Республикасының башка муниципаль берәмлекләре, Россия Федерациясе субъектлары тәҗрибәсе өйрәнелергә, башка эш формалары кулланылырга мөмкин.

9. Мониторинг әлеге нигезләмәнең 6 пунктында күрсәтелгән актларны, федераль, республика һәм муниципаль дәрәҗәдәге норматив хокукый актларны дәгъвалау эшләре буенча суд актларын, прокурор йогынтысы актларын анализлау юлы белән гамәлгә ашырыла.

10. Мониторингны гамәлгә ашыру, җирле үзидарә органнарының норматив базасын анализлау, шулай ук мониторинг йомгаклары буенча

үткәрелгән нормалар иҗат итү эше нәтиҗәләрен фиксацияләү максатларында, муниципаль берәмлекнең җирле үзидарә органнарында муниципаль норматив хокукый актлар реестрларын оештыру һәм алып бару тәртибе турында муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы карары нигезендә башкарыла торган муниципаль норматив хокукый актлар реестрлары файдаланыла.

11. Мониторингны гамәлгә ашыру процессын оптимизацияләү өчен мәгълүмат системаларының автоматлаштырылган сервислары кулланыла (контрактлар, аларның операторлары белән килешүләр төзүгә бәйле күрсәтелгән мөмкинлекләр булганда):

“Гарант” мәгълүмат системасында закон чыгару һәм башка норматив хокукый актларга контрольгә куелган үзгәрешләр турында мәгълүмат керү;

“Гарант” мәгълүмат системасын хокукый җайга салуның тиешле өлкәләре буенча яңалыклар тасмалары мәгълүматы керү;

“Кодекс” мәгълүмат компаниясенең “Региональ законнар аналитигы” автоматлаштырылган мәгълүмат системасы мәгълүматы керү.

Мониторингны гамәлгә ашыру процессын оптимальләштерү максатларында башка мәгълүмат системалары сервислары файдаланыла ала.

12. Муниципаль хокукый актларны кабул итүне (бастырып чыгаруны) тәэмин итү, әлеге нигезләмәнең 9 пунктында күрсәтелгән анализ белән бергә үз көчләрен югалтуын (гамәлдән чыгаруны) тану өчен мониторингны гамәлгә ашырганда түбәндәге критерийлар буенча муниципаль актларны куллану практикасы турында мәгълүмат гомумиләштерелә һәм бәяләнә:

кеше һәм гражданның гарантияләнгән хокукларын, ирекләрен һәм законлы мәнфәгатьләрен үтәү;

муниципаль актларны кабул итү (бастырып чыгару) зарурлыгы билгеләнгән норматив хокукый актлар булу;

муниципаль актны чыгарганда җирле үзидарә органы компетенция лимитларын үтәү;

муниципаль актта коррупциоген факторлар булу;

иҗтимагый мөнәсәбәтләрне хокукый җайга салу;

юридик-техник характердагы хаталар булу;

муниципаль акт нигезләмәләренең мәгънәсен бозу;

муниципаль хокукый актны кулланганда хокуксыз яисә нигезсез карарлар, гамәлләр (гамәл кылмау);

норматив хокукый актларны куллану практикасы булу;

норматив хокукый актларны куллануның бертөрле практикасы булмавы;

муниципаль актны аңлату мәсьәләләре буенча гаризалар саны һәм эчтәлеге;

муниципаль акт белән җайга салынган мөнәсәбәтләргә бәйле рәвештә гариза бирүчеләрнең таләпләрен канәгатьләндерү (канәгатьләндерүдән баш тарту) һәм аларны кабул итү нигезләре.

13. Муниципаль актларга, җирле үзидарә органнары тарафыннан үзгәрешләр кертүгә китерә торган федераль һәм республика законнарына үзгәрешләр мониторингы нәтиҗәләре буенча ачыкланган очракта:

муниципаль актка үзгәрешләр кертү турында, муниципаль актның үз көчен югалтуын тану турында, яңа муниципаль акт кабул итү турында тиешле муниципаль актлар проектлары эшләнә;

муниципаль актларны күбрәк юридик көч актларына туры китерүгә юнәлдерелгән башка чаралар күрелә.

14. Муниципаль актларны үзгәртү ихтыяҗы тудыручы федераль һәм республика законнары актларына үзгәрешләр кертелгән очракта, мониторинг федераль яки республика актын чыгарганнан соң 30 көн эчендә үткәрелә.

Мониторинг үткәрүгә нигез булып гражданнарның, юридик затларның, шәхси эшкуарларның, дәүләт хакимияте органнарының, муниципаль берәмлекләрнең вәкиллекле органнары депутатларының мөрәҗәгатьләре торса, шулай ук прокуратура мәгълүматы, прокурор җавабы актларыннан тыш, мониторинг “Россия Федерациясе прокуратурасы турында” Федераль закон белән билгеләнгән срокларда карала торган карарлардан тыш, алар кергән көннән 30 көн эчендә гамәлгә ашырыла. Әлеге очракларда мониторинг үткәрү нәтиҗәләре турындагы мәгълүмат мөрәҗәгать итүче затка хәбәр ителә.

Федераль һәм республика законнары актларының ерак перспективада үз көченә керә торган үзгәрешләре ачыкланган очракта, җирле үзидарә органнарының норма чыгару эшчәнлеге планнарына тиешле төзәтмәләр кертү турында тәкъдимнәр кертелә.

## III. Мониторинг нәтиҗәләрен тормышка ашыру

15. Муниципаль акт проектын эшләү һәм мониторинг нәтиҗәләре буенча муниципаль акт кабул итү, әлеге нигезләмәнең 14 пунктындагы өченче абзацында күрсәтелгән очрактан тыш, федераль һәм (яисә) республика законнарының тиешле акты үзгәртелгән мизгелдән ике айдан да соңга калмыйча үткәрелә.

16. Мониторинг үткәрү өчен җаваплы затлар җирле үзидарә органнары җитәкчеләре алдында хисаптан соң килүче айның 5 числосыннан да соңга калмыйча мониторинг нәтиҗәләре турында хисап тота.

16.1. Мониторинг нәтиҗәләре турында хисап (мәгълүмат) үз эченә алырга тиеш:

мониторинг үткәрү объекты турында мәгълүмат;

мониторинг үткәрүнең башкаручылары турында мәгълүмат; мониторинг үткәрү чоры турында мәгълүмат;

хокукый җайга салу предметының кыскача характеристикасы, мониторинг үткәрү нигезләре.

1.2. Мониторинг нәтиҗәләре турында хисапта (белешмәләрдә) түбәндәгеләр булырга мөмкин:

хокукый җайга салуның ачыкланган проблемалары турында мәгълүмат;

муниципаль актларга үзгәрешләр кертү һәм (яисә) яңа муниципаль актларны кабул итү, муниципаль актларны юкка чыгару зарурлыгы турында тәкъдимнәр;

тиешле хокукый мөнәсәбәтләр өлкәсендә хокукый җайга салуны камилләштерүгә юнәлдерелгән мониторинг нәтиҗәләренә нигезләнгән башка нәтиҗәләр һәм тәкъдимнәр.

17. Мониторинг нәтиҗәләре буенча кабат кабул ителгән муниципаль актлар Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары

регистрына законнар белән билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда кертү өчен җибәрелә.

Әлеге регистрга кертү өчен анда теркәлмәгән, мониторинг нәтиҗәләре буенча ачыкланган муниципаль актлар җибәрелә.

18. Мониторинг нәтиҗәләре буенча норма чыгару процессын камилләштерү буенча тәкъдимнәр әзерләргә мөмкин.

## IV. Җаваплылык

19. Мониторинг үткәрү һәм хокукый иҗат итү эшчәнлеге өчен җаваплы затлар мониторингны оештыру, шулай ук муниципаль актларны җирле үзидарә органнары карамагына караган тиешле хокукый җайга салу өлкәсендә федераль һәм республика законнарына туры китерү өчен дә җаваплы.

20. Тискәре нәтиҗәләргә, шул исәптән гражданнарга, юридик затларга, җәмгыятькә һәм дәүләткә зыян китергән мониторинг нәтиҗәләре буенча гамәлләр (гамәл кылмау) өчен законнар нигезендә җирле үзидарә органнары җитәкчеләре җаваплы.